**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында гражданнар җыены карары**

12 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- ремонт, киртәләр кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (чүп үләннәргә каршы көрәш, бензин генераторы, триммер, бензопила сатып алу);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (урамнарны яктырту яктырткычлары сатып алу);

- Лашчы тимер юл разъезды поселогында урамнарны яктырту җайланмасы (ял паркында яктырту линиясен капиталь ремонтлау).

3. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы _________ М.К.Истиев

Гражданнар җыены секретаре _________ И.Р.Гибадуллина